ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.06.2019 №1008

2019 елда гражданнар кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексы, "Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2015 елның 16 мартындагы ТРЗ- 13 санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм даими яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләргә (1 нче кушымта):

1.1. һәр гаилә әгъзасы яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең максималь күләме:
1.1.1 ялгыз яшәүче граждан өчен-23 569,70 сум;
1.1.2 ике кешелек гаилә өчен -14 998,90 сум;
1.1.3 өч һәм аннан да күбрәк кешелек гаилә өчен– 12 856,20 сум;
1.2. гражданнар мөлкәтенә салым салынырга тиешле бәянең максималь күләме:
1.2.1 ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 523 610,00 сум;
1.2.2 ике кешелек гаилә өчен - 1 939 140,00 сум;
1.2.3 өч кешелек гаилә өчен – 2 493 180,00 сум;
1.2.4 дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240,00 сум;
1.2.5 биш кешедән торган гаилә өчен -4 153 300,00 сум;
1.2.6 алты кешедән торган гаилә өчен -4 986 360,00 сум;
1.2.7 җиде кешедән торган гаилә өчен -5 817 420,00 сум;
1.2.8 сигез кешедән торган гаилә өчен - 6 648 480,00 сум.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлегенә гражданнарны торак урыннар

бирелүгә мохтаҗлар исәбенә куйганда әлеге карарның 1.1. һәм 1.2. пунктларында күрсәтелгән иң чик күләмне билгеләү нормаларын кулланырга.

3. Әлеге карарны рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы О.А. Никитина

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Башкарма комитетының
24.06 2019 ел, 1008 нче санлы карарына
Кушымта

**Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнарга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләүгә исәп-хисабы**

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече
СЖ = НП х РСхРЦ, монда
СЖ-исәп-хисап күрсәткече;
НП-гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС-гаилә әгъзалары саны;
РЦ - ТР буенча РФ төбәкләр үсеше Министрлыгы раслаган торак урын мәйданының бер квадрат метрына уртача исәпләнгән базар бәясе:
   1) ялгыз яшәүче кеше өчен:
   **СЖ = 33 х 46170 = 1 523 610,00** сум.
   2) ике кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 42 х 46170 = 1 939 140,00** сум.
   3) өч кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18 х 3 х 46170 = 2 493 180,00** сум.
   4) дүрт кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18 х 4 х 46170 = 3 324 240,00** сум.
   5) биш кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18 х 5 х 46170= 4 153 300,00** сум.
   6) алты кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18 х 6 х 46170 = 4 986 360,00** сум.
   7) җиде кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18 х 7 46170 = 5 817 420, 00** сум.
   8) сигез кешедән торган гаиләгә:
   **СЖ = 18х8х 46170 = 6 648 480,00** сум.

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләмен исәпләү.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык

җыелма керемнең максималь күләмен исәпләү формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС), монда

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ хисап бәясе буенча торак урыны сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак алу фондыннан торак алу базар бәясенең исәп күрсәткече;

СЖ = НП х РСх РЦ, монда:

НП-гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ - Татарстан Республикасында торак урыны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен башкарма хакимиятнең тиешле федераль органы тарафыннан билгеләнгән мәйданы бер квадрат метрның уртача базар бәясеннән артмый торган базар бәясе.

ПС-кредит буенча процент ставкасы бер ай эчендә (еллык 12,0%/12 ай =1);

КП - кредит буенча бөтен вакыты өчен түләүләрнең гомуми саны (180 ай);

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык керемнәре белән чагыштырмасы.

Торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2019 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2018 елның 19 декабрендәге 822/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы буенча 46 170 сум күләмендә.

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү.

1) ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1 523 610 х 1 / (1 - (1 + 1) - 180) / (0,25 х 1) = 23 569,70 сум.

2) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1 939 140 х 1 / (1 - (1 + 1) - 180) / (0,25 х 2) = 14 998,90 сум.

3) өч һәм аннан да күбрәк кешелек гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС) - 0,7 х 2 493 180 х 1 / (1 - (1 + 1) - 180) / (0,25 х 3) = 12 856,20 сум.